**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_24_» ___11____ 2025 ел.** **№ __232___**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 24 маендагы 134 номерлы «Физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм күнегүләр үткәрү чараларының календарь планына кертелгән чыгымнар нормалары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 09 апрелендәге 208 номерлы «Татарстан Республикасы спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм күнегүләр чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турындагы 2015 елның 18 мартындагы 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында "гы карары нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 24 маендагы 134 номерлы «Физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм күнегүләр үткәрү чараларының календарь планына кертелгән чыгымнар нормалары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-күнекмә чараларын уздырганда спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм белгечләрне туклану белән тәэмин итү чыгымнарының күрсәтелгән карар белән расланган нормаларына түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-күнекмә чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм белгечләрне туклану белән тәэмин итүгә нормативтан тыш чыгымнарны каплау оешмаларның эшкуарлык һәм керем китерә торган башка эшчәнлектән алган акчалары исәбеннән, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

1.2. физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-күнекмә чараларын уздырганда спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм белгечләрне яшәү белән тәэмин итү чыгымнарының күрсәтелгән карар белән расланган нормаларына түбәндәге эчтәлекле

искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. Физкультура-савыктыру, спорт һәм укыту-күнекмә чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренер-укытучыларны һәм белгечләрне яшәү белән тәэмин итүгә нормативтан тыш чыгымнарны каплау оешмаларның эшкуарлык һәм керем китерә торган башка эшчәнлектән алган акчалары исәбеннән, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов